**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8036**
**02.12.2024**

2024-2025 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннарын билгеләү турында

Карны үз вакытында чыгаруны тәэмин итү һәм кар өюне тәртипкә салу максатларында, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 190 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2024-2025 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урынын билгеләргә:

1) кадастр номеры 16:52:000000:5172, мәйданы 10 га булган җир участогы территориясендә;

2) кадастр номеры 16:52:000000:5342 булган җир участогы территориясендә;

3) кадастр номерлары 16:52:100305:74, 16:52:100305:105 һәм 16:52:100305:8 булган җир участоклары арасында урнашкан, мәйданы 3 га булган, формалаштырылмаган җир участогы территориясендә;

4) кадастр номерлары 16:52:100305:358, 16:52:100305:102 һәм 16:52:100305:22 булган җир участоклары арасында урнашкан, мәйданы 2 га булган, формалаштырылмаган җир участогы территориясендә;

5) Казан проспекты, Иске Сарман урамы, кадастр номерлары 16:52:080504:321 һәм 16:52:080504:836 булган җир участоклары арасында урнашкан, мәйданы 8 га булган, формалаштырылмаган җир участогы территориясендә.

2. 2024-2025 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннарының урнашу схемасын кушымтада каралганча расларга.


3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 2 декабрендәге
8036 номерлы карарына
кушымта

2024-2025 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннарының урнашу схемасы




Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева